**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **14 ноябрь 2020 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Әгерҗе авыл җирлегенә керүче Мәнәвез
авылында 2021 елдаүзарасалым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә, 1 төркем инвалидлар, укучыларның көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:
   - мини-футбол буенча спорт мәйданчыгы урнаштыру (коймалау өчен материал, футбол капкалары ясау өчен материал алу, спорт инвентаре сатып алу);
   - Мәнәвез авылы мөселман зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (коймалау өчен материал алу, коймаларны ясау һәм урнаштыру, җирлеген ясау,;
   - бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү»);
   - җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (авыл мәдәният йорты, ФАП, балалар бакчасы янындагы территориягә таш түшәү (ташны сатып алу, ташу, тигезләү));
   - трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

2. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а адресы буенча, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 29 йорт каршында, Мәнәвез авылы, Узәк урамы, 60 йорт каршында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әгерҗе авыл жирлеге башлыгы: Н.Н.Хәсәнов